**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

---

**РЕШЕНИЕ**
**12.12. 2019 года**

**Иске Имән авылы**

**КАРАР**
**№ 140**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021,2022 нче еллар план чорына бюджеты турында карар проекты кабул итү турында**

“Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Статья 1

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2020 нче елга бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3 040,0 мең сум күләмендә;
2) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3 040,0 мең сум;
3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022 нче елга бюджетының төп характеристиксын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2021 нче елга фаразланган керменең гомуми күләме 3 146,2 мең сум һәм 2022 нче елга 3 260,9 мең сум күләмендә;
2) 2021 нче елга гомуми чыгымнары күләме 3 146,1 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 80,0 мең сум күләменлә, һәм 2022 нче елга 3260,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвешә расланган чыгымнар 165,0 мең сум күләмендә.
3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2021 елга 0,0 мең сум һәм 2022 нче елга 0,0 мең сум.

3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2021 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.
2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2022 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум кләмендә расларга.
3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2023 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум кхләмендә расларга.

Статья 3

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

Статья 4

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.
2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 5

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 5 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бүлекләр, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне раслау турнида” 2007 ел, 6 нче кушымта нигезендә.

3. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2021 нче елга 0,0 мең сум, 2022 нче елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 6

1.Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү буенча шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 1 563,1 мең сум, 2021 нче елга 1 623,2 мең сум, 2022 нче елга 1 685,3 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен раслау.

2.2020 нче елда Иске Имән авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

Статья 7

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:

1)2020 нче елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр – 2 376, 3 мең сум, 2021 нче елга – 2 475,5 мең сум, 2022 нче елга – 2579,8 мең сум;

2) 2020 нче елга хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр – 92,1 мең сум, 2021 нче елга – 92,2 мең сум, 2022 нче елга- 93,7 мең сум.

Статья 8

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2020 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 9

2020 нче елның 1 нче гыйнварена Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге исеменнән 2019 нче елда бу муниципаль контрактларның шартлары нигезендә Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның Иске Имән авыл җирлеге исеменнән төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты акчасы калдыклары 2020 нче елның 1 нче гыйнварына, 2020 нче елда Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Статья 10

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының казначылык органнары төзелгән киешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 11

Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы "Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Статья 12

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

Статья 13

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова

ОГРН 1021601312974
СТАРО-ИМЯНСКОГО сельского поселения
ИНН 1636001989